

Кешелек дөньясында бер тылсымлы көч яши. Ул — безнең телебез. Халык тел аша чын йөрәктән чыккан матур хисләрен, күңел түрендә яткан тирән кичерешләрен, киң хыялында гәүдәләнә торган изге теләкләрен белдерә.



Телдә халыкның рухы да, табигате дә һәм тормыш-көнкүреше дә чагыла. Тел гасырлар буе яшәп килә. Телнең иҗатчысы — халык. Татар халкының бөек шагыйре Габдулла Тукай, чын халыкның телен, чын халык рухын гасырлар буе үсеп, камилләшеп килгән халык иҗаты әсәрләреннән генә белеп була дип бик дөрес күрсәткән.





Татар теле — дөньяда иң матур тел. Татар теле — ул минем туган телем, ә туган телгә бик сак килергә кирәк, аның диңгездәй киң байлыгы, чишмәдәй саф үзенчәлекләре зур осталык белән дөрес файдаланырга, ул рухи байлыкны сакларга, чиста тотарга кирәк.






Без  татарлар үз телебезне телəп өйрəнəбез, телебезне белергə телибез,телебез белəн горурланабыз. Безнең  туган җиребез – Татарстан. Шуңа күрə без татар телен яхшы белергə һəм чит иллəрдə яшəүче ватандашларыбыз белəн дə татар телендə аралашып яшəргə тиешбез.






Безнең мәктәптә укучыларның 60 проценты — татарлар, шуларның 5 проценты гына татар телен белә.

Калган 55 проценты татар телен белми. Мәктәптә укучыларның 40 проценты – башка милләтләр.

Иң кызыгы – ата-аналары татар булсалар да, балалары туган телен белми, русча сөйләшәләр. Чаралар ярдәмендә гаиләгә татар телен кайтарырга омтылабыз. Гаиләдә туган телдә сөйләшергә кирәк, дип аңлатабыз. Мәктәп кенә бу мәсьәләне хәл итә алмый.



Мисал да китерә алам: ире дә, хатыны да – татарлар. Кызларынын теле татарча ачыла, аның белән барлык әбиләре татар телендә сөйләшә . 6 елдан соң уллары туа, әбиләр аның белән русча сөйләшә. Без гаиләдә ире белән хатыны татарча сөйләшә, ә әбиләре – русча! Моны ничек аңлатып була? Проблема яшь буында гына түгел, өлкән буында да!

Мондый күренеш тә бар: укучылар мәктәптә укыганда туган телләрен өйрәнсә дә, сөйләшми. Мәктәпне тәмамлап, берничә ел үткәннән соң, дусларымның туган телдә сөйләшкәннәрен ишетеп, исем-акылым китә. «Син татарча сөйләшәсеңмени?» – дигәч: «Әйе, мин бит татар », – дип җавап кайтаралар. Бу күренеш белән мин горурланам әлбәттә. Мин узем татар кызы татар мохитендә тәрбияләнеп устем, безнең гаиләдә барлык татар йолалары да үтәлә киләчәгемне дә мин кайда гына яшәсәм, эшләсәм дә тормыш иптәшем мөселман булачак һәм балаларымны татар итеп үстерәчәкмен.